**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** | **БОЕРЫК**

« 07 » февраль 2020 с. Тюлячи № 28

**Теләче муниципаль районы буенча коронавирус инфекциясен кире какмый торган симптомнары булган затларны урнаштыру урынын билгеләү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар кабинетының санитар-эпидемологиягә каршы комиссиясенең 2020 елның 3 февралендәге 4 номерлы «Татарстан Республикасында 2019-nCoV коронавирус инфекциясен кертмәү һәм таралуга юл куймау буенча кичектергесез чаралар турында» карарының 8, 9 пунктларын үтәү максатыннан,

1. Теләче муниципаль районы буенча коронавирус инфекциясен кире какмый торган симптомнары булган затларны урнаштыру урынын "Саба үзәк район хастаханәсе" ДАССУ - инфекция бүлеге билгели:
- авырулар өчен госпиталь;
- провизор госпиталь;
- контрактлы авырулар өчен госпиталь.

2. Татарстан Республикасы Теләче районының Казан-Шәмәрдән автомобиль юлының 78 км адресы буенча урнашкан “Туган авыл” кунакханә-куңел ачу үзәгеν обсерватор итеп билгеләргә.

3. «Теләче үзәк район хастаханәсе» ДАССУ баш табибына (Галиуллин И.И.), Татарстан Республикасы буенча Роспотребнадзор идарәсенең Саба ТБ начальнигына (Фатыйхов Р.С.) Теләче муниципаль районы халкы арасында коронавирус инфекциясен кире какмый торган симптомнары булган затлар турында үз вакытында мәгълүмат бирүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Д.С. Гыйниятуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов